УДК 821.512.145:159.922.7

***С.Г. Сәмитова***

# БАЛАЛАР ПСИХОЛОГИЯСЕН ЧАГЫЛДЫРУДА Ф. ӘМИРХАННЫҢ ИҖАДИ ОСТАЛЫГЫ

В рассказах Ф.Амирхана о детях расскрываются этико-психологические проблемы, возникающие от столкновения ребенка с взрослым миром. Рассказы о сиротах, обездоленных и лишенных самого необходимого будят разум и совесть читателя.

**Ключевые слова:** Фатих Амирхан, рассказы о детях, нравственность, сочувствие ребенку, этико-психологические проблемы, эмоциональное состояние.

Татар әдәбияты классигы Фатих Әмирхан иҗатында балалар өчен яки балалар турында язылган әсәрләр дә бар. Язучы, балалар турында уйланып, тормыштагы, җәмгыятьтәге үзе килешә алмаган мәсьәләләрне күтәрә. Бу – беренче чиратта – бәхет, бәхетле, ирекле кешеләр, тормышның, табигатьнең, кешеләрнең матурлыгы мәсьәләсе.

Фатих Әмирханның тормышта иң әрнеп кабул иткән күренешләренең берсе – ятимнәр тормышы. Бу проблема язучының «Ул үксез бала шул!», «Ай өстендә Зөһрә кыз» хикәяләрендә ачыла. «Ул үксез бала шул!» хикәясендә язучы ятим баланың бәхетсезлеген аның башка балаларның мөнәсәбәте аша ачып бирә. Хикәянең эчтәлеге болай: Гает көнне бөтен бала яңа киемнәрдән, араларында ятим малай Нури гына иске киемнәреннән чыккан. Нури узышып йөгергәндә беренче килә. Шул мизгелдән әле генә уйнап йөргән шат балалар тискәре энергия үзәгенә әверелә. Алар ятим баланың җиңүен күтәрә алмыйлар. Нуриның иске киеме аны кимсетергә, рәнҗетергә сәбәп итеп алына. Яклаучысыз булуы да башка балаларга үзләрендәге бөтен явызлыкны чыгарырга мөмкинлек бирә. Амбицияләр, үз-үзен ярату, хөсетлек – бу сыйфатлар балалар өчен дә хас. Шул ук вакытта, балалар шактый беркатлы булып, үзләрендәге бу сыйфатларны яшереп тә калмыйлар. Балалар теләкләренә ирешә – Нури үзенең фәкыйрьлеген, бәхетсезлеген, көчсезлеген тагын бер кат таный. Бу эпизод түбәндәгечә бирелә:

«Ул, минем шушы сүземне генә көтеп торган шикелле, кинәт кенә коймага таба әйләнде, йөзен койманың бер тактасына сөяде дә кычкырып елап җибәрде:

– Мин үксез бала шул! Әтиәнием булса, минем дә читек-кәвешем булыр иде».

Балалар шул вакытта гына үзләренең гамәлләренең никадәр түбән булуын аңлый. Лирик герой бу күренешнең озак вакытлар күз алдыннан китмәвен дә яза. Бала, тискәре энергиягә каршы тора алмый. Әмма әхлакый яктан җиңү – ятим бала ягында. Ул балалардагы явызлыкны җиңеп чыга, аларда кешелеклелек

сыйфатларын уята. Әмма ятим бала үзен җиңүче санамый. Ул җылы сүзгә, башкалардан шәфкатьлелеккә мохтаҗ.

Америка психологы Карен Хорни күрсәткәнчә, бу очракта шәхес тирән шөбһә хисе кичерә, ә ул хисләрдән вакытында арына алмау, киләчәктә дәвалап булмый торган халәткә китерә. «Бу шөбһәдән арыну очен бала невротик ихтыяҗларны канәгатьләндерә торган: мәхәббәт һәм хуплау, нәрсәдә дә булса узенең башкалардан өстенлеген күрсәтү, җәмгыятьтә танылу, үз-үзе белән горурлану кебек саклангыч стратегия (механизм) кулланырга тели. Соңрак бу ихтыяҗлар, шәхси мөнәсәбәт-аралашуларның нигезенә ятып, шәхеснең әйдәп баручы роленә карап, өч төрле бәйләнештә чагылалар:

– киләчәктә кешеләргә баш июче, үз фикере булмаган, бөтен әйләнә-тирәгә ярарга тырышучы шәхес;

– кешеләрдән читтә йөрүче битараф шәхес;

– кешеләргә карата һәрдаим дошманлык күрсәтүче шәхес» [Асмолов, с. 123].

Нурида ялгызлык һәм чарасызлык, беркемгә дә кирәксезлек, әти-әтисез ятим булу, беркем тарафыннан да кайгыртучанлык тоймау, баланың куркынычсызлык һәм иминлек тойгыларын югалтуга китерә. Бары шушы күренештә генә булса да, ягъни ярышта беренче килеп, әйләнә-тирәдәгеләрнең игътибарын җәлеп итү, үзенең шәхес булуын дәлилләү максаты шундый каршылык белән бәрелешү, Нуриның эчке проблемасын тагын да тирәнәйтә. Ул берни дә эшли алмый, елап читкә китеп бара. Елау, үз чиратында, сабый өчен тирән нигезле кичерешләреннән бераз арыну чарасы да. Елау аша күпмедер дәрәҗәдә ул эчке конфликт яки киеренке халәттән арына.

З. Фрейд теориясе буенча, «шәхеснең структур компонентлары – Эго-Мин, Супер-Эго һәм Ид. «Мин, бер яктан, кешене хайвани инстинктлар белән тулыландыручы Ид, икенче яктан – кешедә булган үз-үзеңне ярату-эгоизм, үзең өчен генә яшәү кебек түбән ихтыяҗларны тыючы («табу») Супер-Эго тәэсирендә формалаша» [Романин, с. 34]. Әгәр шәхес күбрәк социум ихтыяҗларын өстен куеп, аларны Ид таләпләреннән өстен куя икән, анда кискен эчке конфликт туа. Ә бу конфликт, үз чиратында, усаллык, явызлык кылуга, я булмаса, төрле психик авыруларга, хәтта үзенә кул салуга да этәрергә мөмкин. Нуриның исә, беренче килеп үзенең башкалардан өстенлеген күрсәтү теләге бу конфликттан арыну чарасы буларак аңлатылырга мөмкин. Чөнки шушы мохиттә бу балалар арасында, аның башкача үзен күрсәтер, ягъни Супер-Эго, ягъни эгоистлык ихтыяҗларын канәгатьләндерү мөмкинлекләре юк.

Фатих Әмирхан үзе күзәткән, яхшы белгән күренешне тасвирлый. Әлбәттә, якын-тирәдәге күпсанлы ятимнәр тормышы да әдипнең җанын әрнеткән. Фатих Әмирханның бердәнбер апасы яшьтән үлеп киткәч, аның өч баласын Фатих Әмирханның әнисе тәрбияли. Әлбәттә, житеш гаиләдә балалар ятимлек ачысын

тоймасын өчен бөтенесе эшләнгәндер. Әмма ана мәхәббәтен бер кеше дә бирә алмый.

Дусты Габдулла Тукайның тормышыннан, аның ятим балачагыннан да хәбәрдар булып кына калмыйча, ул шагыйрьнең аянычлы язмышын соң көненә кадәр күрә. Г. Тукайның балачагында ата-ана назына, мәхәббәткә булган ихтыяҗы, аларны ала алмавы, үсеп җиткәч тә, шагыйрьнең кешеләр белән мөнәсәбәтендә чагыла. Ул яратырга тели, әмма үзе мәхәббәттән кача, кешеләргә артык ышана, һәм шул ук вакытта бер кешегә дә ышанмый.

Ятим балалар ул чорда күп һәм аларны бик кечкенә яшьтә асрау итеп бирү күренеше татар тормышында да киң таралган була.

Ф. Әмирханның бу герое укучыда кызгану хисе генә уятып калмый, укучы бу темага кайта-кайта уйлана, җанында авырту, әрнү тоя. Ятим малай Нури образы кешенең акылын, намусын уята, кешенең әхлак сыйфатларына мөрәҗәгать итә. Әмма әсәрдә әхлак, кешелеклелек буенча дәрес булса да, мораль уку юк. Әсәр шул ягы белән дә көчле. Нури образы ятимлек, ялгызлык символы дәрәҗәсенә күтәрелгән. Хезмәтче бала образы язучының тәмамланмый калган «Кечкенә хезмәтче» хикәясендә дә сурәтләнә. Тәмамланмаган өзек буенча нәтиҗәләр чыгару авыр булса да, бу әсәр А.П. Чеховның «Спать хочется» хикәясенә ияреп языла башлаган булырга мөмкин дип фаразларга мөмкин. Ике әсәрдә дә бары йокы теләге эшкә ашмастай хыял дәрәҗәсенә ирешкән хезмәтче балалар турында сүз бара.

Ятимлек проблемасы «Ай өстендәге Зөһрә кыз» хикәясендә дә күтәрелә. Әдип бу әсәрен татар халкының Зөһрә кыз турындагы мәгълүм легендасына һәм үги кыз турындагы әкиятләргә нигезләнеп иҗат итә. Беренче карашка, Ф. Әмирхан легенданы әдәбиләштереп язган кебек тәэсир туа. Әмма, әсәрдә сюжетка мөнәсәбәттә язучының уй-фикерләре, тормыштагы аерым вакыйгаларга мөнәсәбәте дә урын алган. Язучының фикере ай һәм Зөһрә йолдыз турындагы эпизодларда ачыла. Хикәя «Әнә шул тулган айга карагыз әле! Ул шундый түгәрәк, шундый бөтен, шундый тулы һәм якты. Ләкин аның яктысында әллә нинди бер моң, бер уйчанлык, бер кайгы бар» дип башлана. Ай ни өчен моңлы соң? Автор айның һәрвакыт мондый булмавын да әйтеп уза: «Беләсезме, борын-борын заманнарда аның яктысы болай моңлы, болай уйчан булмаган. Кешеләрнең йөрәкләренә, җаннарына авырлык салмаган. Җиңел, уенчак һәм шат булган, моңландырмаган, сагындырмаган, тынычландырган, юаткан». Нәрсә үзгәргән соң? Ай бик карт икән, һәм гасырлар буе җир өстен, кешеләр дөньясын күзәткән, кешеләр тормышының, үги ана явызлыгының шаһите булган, көне-төне үги ана тарафыннан рәнҗетелгән Зөһрә кызны җәбердән коткарган. Әмма шул явызлыкны күргән ай, элекке кебек шат елкылдый алмый икән. Авторның ятимнәр турындагы төп фикере Зөһрә йолдыз турындагы эпизодта ачыла: «Йолдыз, яшен тизлеге белән атылып,

Зөһрә кызны айга илтеп тапшырган да, үзе күкнең иң күренә торган бер җиренә барып урнашкан. Үксез татар кызын айга илткән өчен, Ходай Тәгалә аның нурын арттырган, һәм фәрештәләр аңа «Зөһрә йолдызы» дип исем биргәннәр». Димәк, ятимнәрнең хәлен җиңеләйтү изге гамәлләрнең берсе булып чыга. Әмма фольклор әсәрләренә ияреп язылган бу хикәя «Ул үксез бала шул» хикәясендәге көчкә ия түгел. Ул дидактик характерда. Ачыктан-ачык дидактика, үгет-нәсыйхәт еш кына кешене уята, уйландыра алмый.

Һәр кешедә ярату һәм яратылуга ихтыяҗ бар һәм ул ихтыяҗ кешеләргә З. Фрейд дәлилләгәнчә, табигать тарафыннан туганда ук күчә һәм шәхеснең үз-үзенең тормышын, гомерен саклау инстикты – Эрос белән бәйле. Әлбәттә, тормышны белмәгән балада бу ихтыяҗ тагын да зуррак. Баланы ниндидер сәләтләргә ия булганы, ниндидер эш эшләгәне өчен генә түгел, бу дөньяда булуы, дөньяның иң зур кыйммәте – кеше булган өчен ярату кирәк. Ф. Әмирханның «Нәҗип» хикәясендә сүз шул турыда бара. Әлеге әсәрдә балаларның өлкәннәр тормышын аңлап бетермәве, яки, киресенчә, өлкәннәрнең балалар тормышын аңларга теләмәве аркасында килеп чыккан әхлак, этик-психологик проблемалар күтәрелә. Хикәядә Нәҗип исемле малайның күршедә яшәүче Мәрфуга апага булган яратуы аша бөтен уй-кичерешләре – үзен бөтен кешенең аны яратуларын теләве, абыйсыннан көнләшүе, күрше кызын яратуы, үпкәләүләре, шатлыклары тасвирлана. Хикәя Нәҗип исеменнән сөйләнә. Ф. Әмирхан малайның яшен күрсәтми, чөнки Нәҗип үзен инде зур егет дип кабул итә. Баланың шөгыльләре, уй-фикерләре аша гына аның биш яки иң күбе алты яшьләрдә булуы аңлашыла. Нәҗип әлегә мәдрәсәдә укымый, бары хосусый мөгаллим белән өйдә генә шөгыльләнә. Нәҗипнең абыйсы Гомәр курайда уйный. Шуның өчен аны бөтен кеше ярата: «Әгәр инде ул өйдә булса, карчыклар аны чакырып сөяләр, сөйләштерәләр, кызлар аны үзләренең уеннарында катыштыралар, аны кыстап курай уйнаталар иде». Нәҗип абыйсына булган бу мөнәсәбәткә бик кызыгып карый, үзенә дә өлкәннәрнең игътибарын яуларга омтыла. Малай абыйсына булган мәхәббәтнең, курай уйнаганы өчен генә булганын да аңлый. Ул күрше кызы, апасы янына керә торган Мәрфуга апаны ярата. Шунда ук автор малайның уйлары аша мәхәббәтнең икенче төрлесе булуын да әйтеп уза: «Мин аны күзләре зур булганга, тешләре бик тигез, ап-ак булганга һәм авызын матур итеп көлгәнгә сөя идем». Димәк, нәрсәдер эшләгән өчен түгел, бары булган өчен генә дә яратырга мөмкин. Бу эчкерсез бала мәхәббәте. Әлеге вакыйганы тасвирлап, Ф. Әмирхан гаиләдәге иерархия бик үк дөрес төзелмәгән булуын да исбатлый кебек. Әлбәттә, бөтен татар гаиләләренә хас булганча, абый үз урынында, тик сабый гына читтәрәк. Ана да аны теләмәстән рәнҗетә. Шул рәвешле, бала бу гаиләдә үзенең урынын билгели алмый, кирәк-

сезлеген таный, мәхәббәткә лаек түгел, дип уйлый. Бу уйлар аны тирән экзистенциаль конфликтка этәрә.Бу конфликттан арыну өчен ул ниләр генә эшләми: койма башына да менә, Мәрфуга апасының сынын да ясый...

Ф. Әмирхан, баланың үз-үзен тотуындагы көлке мизгелләрне дә, баланың беркатлы, гади, эчкерсез булуын, аның психологиясен аңлап, шуңа күрә дә яратып, теләктәшлек белдереп иҗат итә, дөньяны бала күзләре белән күрә. Бала булып уйлый, шатлана, борчыла. Язучы өчен һәр бала дөньяга карашы, зәвыгы, эчке дөньясы формалашкан шәхес. Әмма бала олылар алдында көчсез, аларның мәхәббәтенә, яклавына һәм аңлавына, җылы мөгамәләсенә мохтаҗ, шул ук вакытта ул олылардан эчкерсезрәк. Күп нәрсәне онытырга, һәрвакыт гафу итәргә әзер.

Нәҗип олыларның мәхәббәтен яулау турында хыяллана. Аның бөтен гамәлләре шуңа юнәлтелгән. Мәсәлән, ул үзен көчле итеп күрсәтергә теләп, абыйсының кураен тартып ала. Бала бу гамәлен начарлык эшләү нияте белән кылмый. Аның максаты – бары үзенә игътибар яулау гына. «Бу эш, минем үземчә, бер егетлек шикелле булып, кунак кызларының, хосусан Мәрфуга апаның исен китерер, һәм аларга мине бер батыр егет итеп күрсәтер шикелле тоела иде». Әмма баланы аңлаучы табылмый. Хәтта әнисенә үзенең проблемасын сөйләгәннән соң да, бала аңлаучы да, яклаучы да таба алмый. Шуның өстенә әни кеше балада үзе турында ялгыш фикер тудырырга җирлек бирүче фикер әйтә: «Абыеңныкы кебек берәр һөнәрең булса, сине дә үзләре чакырып алырлар иде». Малай мәхәббәтне яулау өчен нәрсәдер эшләргә кирәген аңлый. Әмма алты-җиде яшьлек баланың дөньяны аңлавы үзенчәлеклерәк. Ул Мәрфуга апасының игътибарын үзенә җәлеп итәр өчен алга таба нәрсә эшлисен уйлый башлый. Мәрфуга апасын шаккаттырасы килеп, йорт түбәсенә менеп баскач та, баланы аңламыйлар. Аны абыйсы белән чагыштырып, Нәҗипкә аның абыйсыннан кайтыш икәнен исбатлау дәвам итә. Баланың һәр гамәле тәнкыйтьләнә, шул ук вакытта өлкәннәр аның белән сөйләшеп, бала өчен бик авыр тоелган мәсьәләләрне чишү юлларын да күрсәтми. Автор баланың йокларга яткач та уйланып ятуын, үзен гаепли башлавын, гаепне үзеннән эзләвен күрсәтә. Малай өлкәннәр тормышына яраклаша башлый. Аның гаепне үзеннән генә эзләве малайның өлкәннәр битарафлыгы алдында җиңелүен күрсәтә. Өлкәннәр өчен баланың бу борчулары вак мәсьәлә, игътибарга алынырга тиеш түгел.

Нәҗип ахыр чиктә үзенә игътибарны җәлеп итә алырлык шөгыль таба: инде кызлар, бигрәк тә эчкерсез сөйгән Мәрфуга апа, аны еш кына чигү өчен рәсем төшерергә чакыра. Бу эпизод аша да Ф.Әмирханның ни дәрәҗәдә бала психологиясен тирән белүен күрәбез. Нәҗип, беренче чиратта, үзенең бу гаиләдә генә түгел, ә җәмгыятьтә дә үз урынын таба, икенче яктан, сөйгән Мәрфуга апасы янында утыру, аңа үзенә күрә бер ләззәт бирә.

«...Мәрфуга апа минем төшергәннәремне карап тора, кайсыбер сызыклар матур чыгып куйса, ул зур күзләре белән миңа көлемсерәп, иркәләгән шикелле итеп карап ала иде. Чәчәк ясалып бетте; ләкин мин бу күңелле эшемнән тиз генә аерыласым килмәде.

– Мәрфуга апа, бу чәчәк ни өчен кирәк булды сиңа?

– Калфакка чигәргә. Инде ясалып бетте бит ул? Бик рәхмәт сиңа!

– Менә бу җиренә шушы чәчәкнең бөресен дә ясап куйсак, ничек булыр, Мәрфуга апа?» – дигән өзектән кечкенә Нәҗипнең инде бер яктан, эстетик зәвыгы барлыгы күренсә, икенче яктан, аның психологиясе ачыла: ул Мәрфуга апасы янында тагын да озаграк утыра ала һәм, сәләтен күрсәтеп, соклану хисләре уята, үзен инде кирәклеген танып, эчке конфликттан арына. Сәнгать – эстетик тәрбия, ул балада реаль чынбарлыкны әдәби образлар аша сурәтләп, балада дөньяга караш, эстетик зәвык тәрбияли.

Хикәянең өченче өлешендә Нәҗипнең эш-гамәлләре аша үзенә яхшы игътибар алырга өйрәнеп җитүен күрәбез. Өченче өлеш беренче ике өлештән күләменең кечкенә булуы белән аерыла. Бу бүлектә баланың уй-фикерләре, эчке халәтенә дә урын бирелми.

Хикәядә алгы планда Нәҗип образы, аның гамәлләре, уй-фикерләре. Әмма игътибарлы укучы шул ук вакытта икенче картинаны да күрә. Бу балага аңлашылып бетмәгән, еш кына аның борчылуларына сәбәп булган олылар тормышы. Димәк, берьюлы ике картина сурәтләнә. Әдип җәмгыятьнең һәм гаиләнең балага шәхес буларак формалашуда йогынтысын, ролен ача.

Күләме ягыннан зур булмаган бу хикәя үзе дә ике яклы. Беренче карашка, балалар өчен язылган дидактик характердагы әсәр. Икенче яктан, бала хөр фикерле, фикерен якларлык кыю шәхес булып формалашсын өчен аңа игътибар, мәхәббәт кирәклеге турында да. Баланың дөрес адымы, гамәлләре хупланырга, һәм киресенчә булганда, ни өчен алай эшләргә ярамавы аңлатылырга, дөрес чишелеш күрсәтелергә тиеш. Башка бала белән чагыштыру, аның өчен гомере буена бара торган психологик яра булып кала да ала.

Балалар темасы Ф. Әмирханның башка хикәяләрендә дә күтәрелә. Ул бу әсәрләрендә төрле яктан балалар дөньясын ача. Аларның самимилегенә, эчкерсезлегенә соклана. Язучы иҗатында балалар психологиясе мәсьәләләре күтәрелә. Ф. Әмирхан иҗатын шушы яктан да өйрәнү кызыклы нәтиҗәләргә китерә.

**Әдәбият**

*Асмолов А.Г.* Психология личности: Учебник. М.: Изд-во МГУ, 1990. 367 с.

*Әмирхан Ф.* Әсәрләр: Дүрт томда. 1 том. Хикәяләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. 480 б.

*Романин А.Н.* Основы психоанализа. Ростов на Дону.: Феникс, 2003. 315 с.

***Сәмитова Сәвия Гималтдин кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, социаль-гуманитар белем институтының философия һәм гуманитар фәннәр кафедрасы доценты*